| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТСПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|

программа здравоохр

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№6** **от 11.01.2019г.**

**Спас муниципаль районының «2019-2021 елларга халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлүчеләр санын киметү» муниципаль программасын раслау турында**

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өлкәсендәге дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Спас муниципаль районының «2019-2021 елларга халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлүчеләр санын киметү» муниципаль программасын расларга.
2. «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына чараны финанслау акчаларын күздә тотарга.

ТР Спас муниципальрайоны
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А Осокин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1637005464

**Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән РАСЛАНДЫ**

# Спас муниципаль районының «2019-2021 елларга халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлүчеләр санын киметү» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның аталышы | «2019-2021 елларга халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлүчеләр санын киметү» максатчан программасы |
| Программаның заказчысы | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Үзәк район хастаханәсе, ГХАТ бүлеге, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, мәгариф бүлеге, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге. |
| Программаның төп максатлары һәм бурычлары | Яшәеш сыйфатын тотрыклы арттыру, сәламәтлек саклауны үстерү, халыкны алкогольдән һәм наркотиклардан яклау, хезмәт саклау чаралары һәм социаль ярдәм чараларын камилләштерү буенча эзлекле сәясәт үткәрү ярдәмендә үлүчеләр санын киметү.<br>Сәламәт яшәү рәвешенең заманча шартларын һәм пропагандасын булдыру юлы белән кечкенәдән башлап, халык арасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә ихтыяҗ тудыру.<br>Тууучылар санын арттыруга булышлык күрсәтү. Иң мөһим социаль институт буларак гаиләне саклау һәм үстерү. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2019-2021 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | «Спас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Спас муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге, Спас муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге, Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге, Спас муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Спас муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге, Спас муниципаль районы мәдәният бүлеге, Спас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ДКУ, ТР Спас районында Россия Пенсия фонды идарәсе ДУ, шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыклары, Иҗтимагый совет. |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Бөтенесе: 9989,2 мең сум<br>2019 ел 3649,1 мең сум<br>2020 ел 3190,1 мең сум |

| | |
|---|---|
| | 2021 ел 3150,0 мең сум<br>Үзәк район хастаханәсе акчалары<br>Бөтенесе: 246,0 мең сум<br>2019 ел 138,0 мең сум<br>2020 ел 54,0 мең сум<br>2021 ел 54,0 мең сум<br>Җирле бюджет акчалары<br>Бөтенесе: 9743,2 мең сум<br>2019 ел 3511,1 мең сум<br>2020 ел 3136,1 мең сум<br>2021 ел 3096,0 мең сум<br>Спас муниципаль районы бюджетына керүче салым һәм салым булмаган керемнәр, шулай ук бюджеттан тыш трансфертлар хисабына, Спас муниципаль районы бюджетының керем өлешен үтәүгә бәйле рәвештә, программада чараларны үтәүгә каралган акча күләмнәре үзгәрергә мөмкин. |
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән ахыргы нәтиҗәләр | 1. 2021 елга үлүчеләр санын 2018 ел дәрәҗәсенә карата 10%ка киметү.<br>2. 2021 елга хезмәткә яраклы яшьтә үлүчеләр санын 10%ка киметү.<br>3. Халыкның гомер озынлыгын арттыру, халыкның тормыш сыйфатын, сәламәтлек торышын яхшырту. |
| Программа үтәлешен контрольдә тоту | Спас муниципаль районы Башкарма комитеты |

## 1. Программа хәл итәргә тиешле проблеманың характеристикасы

Халык сәламәтлеген саклау һәм ныгытуның дәүләт сәясәтен фомалаштыру өстенлекле бурычларның берсе булып тора. Сәламәтлек саклау системасында тамырдан яңа юнәлеш үсеш алды – авыруны дәвалауга юнәлдерелгән системадан сәламәт яшәү рәвеше өстенлегенә йөз тоткан һәм авыруларны кисәтүгә юнәлтелгән гражданнар сәламәтлеген саклау системасына күчү.

Проблеманың актуальлеге шунда ки, аерым уңай күренешләргә карамастан,
сәламәтлек күрсәткечләре һәм сәламәтлек саклау торышы түбән дәрәҗәдә кала бирә. Дәүләтнең катлаулы икътисадый һәм социаль үсеш шартлары авыручылар һәм үлүчеләр санының гаять югары күрсәткечләрендә, туучылар санының, аналар һәм балалар сәламәтлеге торышының түбән дәрәҗәсендә чагылыш тапты. Моннан тыш, хәзерге вакытта халык сәламәтлегенең социаль бәйлелекле һәм профессиональ сәбәбе булган дефектлары көчәя бара.

Халык сәламәтлеген ныгыту һәм үлүчеләр санын киметү программасы бүген районның муниципаль хакимияте органнары, социаль тәэмин итү һәм

сәламәтлек саклау өлкәләрендә кичекмәстән хәл итү өчен беренчел дәрәҗәгә чыгарыла. Халык сәламәтлеген, медицина хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен, демографик хәлне, хезмәт саклау, физик культура һәм спорт үсешен сыйфатлый торган кайбер аспектларга мөрәҗәгать итсәк, проблема тагын да ныграк аңлашыла.

## 1.1 Демографик хәлгә анализ

Үлүчеләр санының югары күрсәткече районда халык саны кимүнең төп сәбәбе булып тора. 1993 елдан башлап районда үлүчеләр саны туучылар санынннан артып китте һәм озак вакытлы тотрыклы күренешкә әйләнде.

**1 нче таблица**

**1990-2017 елларда туучылар һәм үлүчеләр саны турында мәгълүмат**

| Ел | Туучылар саны (кеше) | Үлүчеләр саны (кеше) | Табигый артым (+/-) |
|---|---|---|---|
| 1990 | 390 | 310 | +80 |
| 1991 | 314 | 218 | +96 |
| 1992 | 325 | 319 | +6 |
| 1993 | 292 | 411 | -119 |
| 1994 | 323 | 428 | -105 |
| 1995 | 261 | 381 | -120 |
| 1996 | 219 | 317 | -98 |
| 1997 | 227 | 339 | -112 |
| 1998 | 245 | 362 | -117 |
| 1999 | 242 | 356 | -114 |
| 2000 | 248 | 397 | -145 |
| 2001 | 219 | 380 | -161 |
| 2002 | 225 | 369 | -144 |
| 2003 | 264 | 460 | -196 |
| 2004 | 198 | 404 | -206 |
| 2005 | 203 | 476 | -273 |
| 2006 | 171 | 390 | -219 |
| 2007 | 199 | 415 | -216 |
| 2008 | 203 | 395 | -192 |
| 2009 | 211 | 414 | -203 |
| 2010 | 224 | 390 | -166 |
| 2011 | 224 | 372 | -148 |
| 2012 | 214 | 353 | -139 |
| 2013 | 255 | 336 | -81 |
| 2014 | 249 | 341 | -92 |
| 2015 | 188 | 350 | -162 |
| 2016 | 160 | 316 | -156 |
| 2017 | 166 | 309 | -143 |

Район халкы табигый хәрәкәтенең гомуми коэффициентларын чагыштырсак, бу ныграк аңлашыла. Иң югары табигый кимү дәрәҗәсе 2005 елда күзәтелде.

**2 нче таблица**

**Спас районы халкы табигый хәрәкәтенең гомуми коэффициентлары (1000 кешегә)**

| Еллар | Туучылар | Үлүчеләр | Табигый артым (киму) |
|---|---|---|---|
| **1998** | **10,7** | **15,7** | **-5,0** |
| **1999** | **10,6** | **15,7** | **-5,1** |
| **2000** | **11,2** | **17,7** | **-6,5** |
| **2001** | **9,6** | **17,1** | **-7,5** |
| **2002** | **10,5** | **18,0** | **-7,5** |
| **2003** | **12,4** | **21,0** | **-9,2** |
| **2004** | **9,6** | **18,8** | **-9,2** |
| **2005** | **10,2** | **22,1** | **-11,9** |
| **2006** | **9,0** | **18,9** | **-10,1** |
| **2007** | **10,9** | **20,0** | **-9,1** |
| **2008** | **11,7** | **19,4** | **-7,7** |
| **2009** | **10,4** | **20,4** | **-10,0** |
| **2010** | **10,9** | **18,9** | **-8,0** |
| **2011** | **11,0** | **18,2** | **-7,2** |
| **2012** | **10,6** | **17,5** | **-6,9** |
| **2013** | **12,8** | **16,8** | **-4,0** |
| **2014** | **12,6** | **17,2** | **-4,6** |
| **2015** | **9,6** | **17,9** | **-8,3** |
| **2016** | **8,2** | **16,2** | **-8,0** |
| **2017** | **8,5** | **15,9** | **-7,4** |

Туучылар һәм үлүчеләр саны динамикасын тәкъдим ителгән график ачык чагылдыра.

**3 нче таблица**

**Спас муниципаль районында туучылар һәм үлүчеләр исәбенең динамикасы (1000 кешегә)**




| | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Туучылар* | *10,2* | *9* | *10,9* | *11,7* | *10,4* | *10,9* | *11* | *10,6* | *12,8* | *12,6* | *9,6* |
| *Үлүчеләр* | *22,1* | *18,9* | *20* | *19,4* | *20,4* | *18,9* | *18,2* | *17,5* | *16,8* | *17,2* | *17,9* |
| *Табигый артым (киму)* | *-11,9* | *-10,1* | *-9,1* | *-7,7* | *-10* | *-8* | *-7,2* | *-6,9* | *-4* | *-4,6* | *-8,3* |

2011-2015 еллар чорында табигый кимү күрсәткече кими башлады. Әмма, 2016-2017 елларда табигый кимү арта. Әлеге программаның бурычы – районда табигый кимүнең түбәнәюен кайтару.

Берничә ел дәвамында үлүчеләр саны структурасында кан әйләнеше системасы авырулары өстенлек итә, икенче урында – яман шешләр, өченчедә – тышкы сәбәпләр.

**4 нче таблица**

**Үлем сәбәбе структурасы (%)**

| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Кан әйләнеше системасы авырулары, шул исәптән | 63,8 | 52,8 | 51,3 | 44,9 | 48,6 |
| *миокард инфаркты* | *1,9* | *3,7* | *5,3* | *5,9* | *3,4* |
| *инсульт* | *15,4* | *9,6* | *11,9* | *6,7* | *4,6* |
| Яман шешләр | 9,5 | 11,9 | 12,5 | 12,3 | 14,9 |
| Тышкы сәбәпләр | 8,6 | 8,2 | 10,4 | 7,0 | 12,3 |

Саннар үлем сәбәпләре арасында беренче баскычларны кан әйләнеше системасы авырулары алып торуын күрсәтә, 63,8-48,6 процент. Алга таба яман шешләр, үлемнең тышкы сәбәпләре, сулыш органнары авырулары, ашкайнату органнары авырулары, йогышлы һәм паразитар авырулар, туберкулез килә.

Хезмәткә яраклы яшьтә үлүчеләр саны гаять тискәре күренеш булып тора. Үлүчеләр арасында тормыш юлына әле яңа баскан яшьләр күп.

**1 нче график**

**Хезмәткә яраклы яшьтә үлүчеләр саны, кеше**




**5 нче таблица**

| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Кан әйләнеше системасы авырулары, шул исәптән | 31 | 28 | 24 | 23 | 18 |
| *миокард инфаркты* | *3* | *5* | *7* | *10* | *5* |
| *инсульт* | *5* | *3* | *3* | *5* | *2* |
| Яман шешләр | 12 | 12 | 11 | 10 | 11 |
| Тышкы сәбәпләр | 24 | 24 | 26 | 15 | 27 |
| Барлыгы | 75 | 72 | 71 | 73 | 63 |

Тәкъдим ителгән графиктан күренгәнчә, 2014-2018 еллар чорында хезмәткә яраклы яшьтә үлем структурасында алдынгы урыннарны тышкы сәбәпләр алган, икенче урында элеккечә яман шешләр.

Туучылар һәм үлүчеләр саны демографиянең иң мөһим күрсәткечләре генә түгел, ә гомумән, социаль-икътисадый үсешнең төп интеграль характеристикалары да. Халыкның табигый артымына, үлүчеләр саны кимүгә, гомумән, халык сәламәтлегенә аеруча кискен йогынты ясаучы кайбер аспектларны карыйк.

**6 нчы таблица**

**Спас районының авыр җирлекләре буенча**
**үлүчеләр саны**

| | 2017 | 2018 |
|---|---|---|

| | Бөте-несе | Үлү-че-ләр-нең урта-ча яше | Хез-мәткә ярак-лы яшь | 80 яшь-тән өл-кән-рәк | Туды | Бө-те-несе | Үлү челә рнең урта ча яше | Хез-мәткә ярак-лы яшь | 80 яшь-тән өл-кән-рәк | Туды |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шәһәр* | 135 | *70,7* | *16* | *48* | *111* | 126 | *69,3* | *28* | *45* | *104* |
| *Аграмак* | *6* | *57,2* | *3* | *1* | *3* | *10* | *80,7* | *-* | *8* | *3* |
| *Антоновка* | *13* | *69,5* | *4* | *7* | *11* | *8* | *68,6* | *3* | *4* | *1* |
| *Бураково* | *11* | *76,3* | *2* | *6* | *1* | *13* | *76,0* | *2* | *5* | *-* |
| *Әҗмәр* | *12* | *63,3* | *5* | *3* | *5* | *15* | *76,3* | *1* | *8* | *5* |
| *Иске Рәҗәп* | *24* | *76,5* | *2* | *13* | *1* | *26* | *72,7* | *4* | *12* | *-* |
| *Кузнечиха* | *14* | *65,6* | *4* | *5* | *5* | *1* | *72,0* | *-* | *-* | *3* |
| *Кызыл Бистә* | *13* | *75,2* | *3* | *7* | *5* | *9* | *72,3* | *2* | *3* | *2* |
| *Ким* | *11* | *54,3* | *7* | *2* | *8* | *14* | *63,6* | *6* | *2* | *8* |
| *Куралово* | *9* | *68,9* | *2* | *3* | *1* | *14* | *67,9* | *5* | *4* | *4* |
| *Никольский* | *21* | *65,7* | *5* | *5* | *3* | *19* | *69,9* | *3* | *12* | *5* |
| *Полянка* | *15* | *69,9* | *3* | *5* | *8* | *18* | *63,9* | *2* | *5* | *3* |
| *Приволжский* | *8* | *70,3* | *1* | *3* | *1* | *16* | *67,6* | *2* | *7* | *2* |
| *Чәчәкле* | *8* | *73,5* | *2* | *4* | *1* | *7* | *80,1* | *-* | *2* | *-* |
| *Урта Йорткүл* | *9* | *69,2* | *2* | *5* | *3* | *13* | *73,3* | *2* | *5* | *-* |
| *Өчкүл* | *9* | *73,7* | *1* | *4* | *10* | *14* | *66,6* | *5* | *3* | *9* |
| *Ямбакты* | *7* | *77,4* | *-* | *2* | *2* | *9* | *66,4* | *1* | *3* | *-* |

## 1.2. Халык эчкечелеге

Үлүчеләр саны үсешенә, аеруча яшь һәм балигъ булган яшьтә алкоголь, шул исәптән суррогат, наркотиклар һәм башка психотроп матдәләр куллану тискәре йогынты ясый.

7 нче таблицаны карыйк.

**7 нче таблица**

**2014-2018 елларда табиб-наркологта исәптә торучы диспансер авырулары**

| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Алкоголизм, шул исәптән стадияләр белән | 306 | 306 | 304 | 296 | 294 |
| башлангыч (I) | 105 | 98 | 98 | 98 | 96 |
| урта (II) | 201 | 208 | 206 | 198 | 198 |
| Наркомания | 2 | 2 | 2 | 3 | 1 |
| Токсикомания | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 |

2016 елдан башлап «Спас үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә табиб психитар-нарколог эшкә урнаштырылды, бу диспансер исәбендә торучы алкогольгә бәйлелеге булган пациентлар санының 2016 елда 306дан 2018 елда 294кә кадәр кимүенә китерде.

**8 нче таблица**

**Сәүдә нокталарында алкоголь продукциясен сату**

| Чор | Алкоголь продукциясе сатылган (литрларда) | Җан башына (литрларда) |
|---|---|---|
| 2014 ел | 270224 | 13,2 |
| 2015 ел | 259293 | 12,8 |
| 2016 ел | 196507 | 9,8 |
| 2017 ел | 171075 | 8,6 |
| 2018 ел | 159017 | 8,1 |

Шулай ук рәсми статистика мәгълүматлары буенча районда сатылган алкоголь продукциясе саны 2014 елда 270224 литрдан 2018 елда 159017 литрга кадәр кимегән.

Шул ук вакытта 2016 елдан башлап җәмәгать урыннарында спиртлы эчемлекләр кулланган һәм исерек хәлдә күренгән өчен җәлеп ителүчеләр саны шактый арткан. Мәгълүматлар графикта күрсәтелде.

**2 нче график**




Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, алкоголь кулланучылар саны кимемәгән. Эчкечелек белән авыручы кешеләр сыйфатсыз, ялган алкоголь продукциясен торган саен күбрәк куллана башлаган.

## 1.3. Өйләнешүләр һәм аерылышулар

Яшәеш дәрәҗәсе иминлегенә, сәламәтлек торышына өйләнешүләр һәм аерылышулар тенденциясе турыдан-туры йогынты ясый. Әүвәл 9 нчы таблицаны карыйк.

**9 нчы таблица**

**Тулы булмаган гаиләләрдә балалар саны**

| Еллар | Өйләнешүләр саны | Аерылышулар саны | Аерылышканнан соң тулы булмаган гаиләдә калган балалар |
|---|---|---|---|
| **2014** | **151** | **65** | **45** |
| 2015 | 122 | 49 | **53** |
| **2016** | **114** | **60** | **49** |
| **2017** | **124** | **60** | **40** |
| **2018** | **108** | **62** | **48** |

Соңгы 5 елда аерылышулар теркәлгән никахлар санына карата 48% тәшкил иткән. Әмма аерылышулар бар икән, димәк, тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар да бар. Елына уртача 47 бала әтисе яки әнисе белән генә кала. Бу, нигездә, ата-аналары аерылышудан психик травма алган һәм еш кына тулы канлы туклану алу мөмкинлеге булмаган балалар.

Соңгы елларда гражданнарча гына берләшеп яшәүче парлар саны артты, киләчәктә аларның барысы да рәсми теркәлә, дип әйтеп булмый.

9 нчы таблицага мөрәҗәгать итик, анда аерылышулар саны якынча тигез булганда, никахлар санының өчтән бергә диярлек кимүе ачык күренә.

**10 нчы таблица**

**Спас муниципаль районы буенча туучылар саны турында мәгълүмат**

| Еллар | Туучылар саны (кеше) | Теркәлмәгән никахларда туган балалар саны (кеше) | % |
|---|---|---|---|
| **2014** | **224** | **52** | **23,2** |
| 2015 | 214 | 55 | 25,7 |
| **2016** | **255** | **57** | **22,4** |
| 2017 | 249 | 48 | 19,3 |
| 2018 | 188 | 46 | 24,5 |

Әгәр 2014 елда теркәлмичә яшәүче парлардан 52 бала туган булса, ә бу барлык туучылар санының – 23,2%ы, 2018 елда шундый 46 бала туган, ягъни барлык туучылар санының 24,5%ы. Биредә туучылар саны кимү белән беррәттән өйләнешмичә тудырылган балалар процентының артуы күзәтелә.

Җәмгыятьтә социаль иминлек дәрәҗәсе, гаилә институты гамәлдә булуның нәтиҗәлелеген яки нәтиҗәсезлеген өйләнешүләр һәм аерылышулар нисбәте күрсәткече чагылдыра. 2016 һәм 2018 елларда әлеге күрсәткечнең кимүе күзәтелде.

**11 нче таблица**

**Өйләнешүләрнең һәм аерылышуларның нисбәте**

| еллар | 1000 кешегә өйләнешүләр саны | 1000 кешегә аерылышулар саны | Өйләнешүләр һәм аерылышулар нисбәте |
|---|---|---|---|
| **2014** | **151** | **65** | **2,3** |
| **2015** | **122** | **49** | **2,5** |
| **2016** | **114** | **60** | **1,9** |
| **2017** | **124** | **60** | **2,1** |
| **2018** | **108** | **62** | **1,7** |

**3 нче график**

**Фертиль яшьтәге хатын-кызлар саны (15-49 яшь)**




Әлеге графикта фертиль яки бала табу яшендәге хатын-кызлар санының кимү тенденциясе күрсәтелгән. Районыбызга яшь, хезмәткә яраклы кешеләрнең күчеп килүе килеп туган хәлдән чыгу юлы булырга мөмкин. Бәлки, бу җәһәттән, безгә Болгар тарихи-архитектура тыюлыгын үстерү ярдәм итәр.

Өйләнешүләрнең һәм аерылышуларның совет чоры өчен хас булган, гаилә институты үсешендә иминлекне чагылдырган 2,5 һәм аннан артыграк нисбәте соңгы 5 елда 2015 елда гына күзәтелде.

## 1.4. Гомер озынлыгы

Халыкның сәламәтлек торышы һәм үлүчеләр саны дәрәҗәсе чагылышы булып кеше туган вакытта көтелгән гомер озынлыгы күрсәткече тора. Үлүчеләр санының югары дәрәҗәсе көтелгән гомер озынлыгының түбән күрсәткечләрен билгели. Район халкының гомер озынлыгы динамикасын 12 нче таблица күрсәтә.

**12 нче таблица**

**Спас районы буенча көтелгән гомер озынлыгы**

| | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
|---|---|---|---|---|---|
| Ирләр | 63,91 | 61,05 | 61,05 | - | - |
| Хатын-кызлар | 76.14 | 76,39 | 76,38 | - | - |
| Ирләр һәм хатын-кызлар | 69.61 | 68,27 | 68,27 | 72,2 | 72,43 |
| ТР буенча ирләр һәм хатын-кызлар | 71.41 | 71,90 | 72,19 | 72,51 | 72,84 |

2014 елда үлүчеләр саны 372 кеше тәшкил итте (бу иң югары күрсәткеч). Уртача гомер озынлыгы 69,61 ел тәшкил итә, өстәвенә, хатын-кызлар – 76 ел, ирләр – 64 ел, аерма – 12 яшь. Шунысын искәртик, республика буенча әлеге күрсәткеч ел саен арта бара.

## <u>1.5. Үлем проблемаларына сыйфатлама һәм аларны хәл итүдә төп юнәлешләр:</u>

### 1.5.1. Кан әйләнеше системасы авырулары.

Ел саен дөньяда кан әйләнеше системасы авыруларыннан дистәләгән миллион кеше үлә, шул исәптән йөрәкнең ишемик авыруыннан – 7 миллионнан артык.

Россия Федерациясендә хезмәткә яраклы халыкның йогышлы булмаган авырулар аркасында вакытыннан алда үлем структурасында кан әйләнеше системасы авырулары өлешенә ирләр арасында – барлык үлүчеләр санының 36,6%ы, хатын-кызлар арасында 40,5%ы туры килә.

Кан әйләнеше системасы авырулары артуга һәм көчәюгә йогынты ясаучы әйдәп баручы риск факторы булып артериаль гипертония тора, ул россиялеләр арасында 39,0% очракта ирләрдә һәм 41,0% очракта хатын-кызларда теркәлгән. Россия Федерациясе буенча гомумән алганда артериаль гипертонияле 41 млн. артык авыру теркәлгән. 40 яшькә чаклы артериаль гипертония белән авыручыларда киләчәк гомернең уртача озынлыгы 6 елга кыскара.

Татарстан Республикасында, Россия буенча гомумән булган кебек, өлкән яшьтәге кешеләрнең кан әйләнеше системасы чирләре белән авыруының артуы күзәтелә.

Хәзерге вакытта республикада артериаль гипертониядән җәфа чигүче 300 меңгә якын кеше теркәлгән, ягъни бу һәр унынчы кеше дигән сүз.

2018 елда ТР буенча үлем структурасында (алдагы еллардагы кебек үк) кан әйләнеше системасы авырулары өстенлек итә – 51,1 % (2017 ел – 51,7 %); күрсәткеч 100 мең кешегә 607,3 тәшкил итте, бу 2017 елгы күрсәткечтән 3,4%ка кимрәк (РФ – 631,8; ИФО – 659,7).

Татарстан Республикасы буенча гипертония авыруыннан үлүчеләр саны 8,2%ка кимеде, һәм 100 мең кешегә 41,4 тәшкил итте (2017 ел – 45,0), гипертония авыруы өзлегүләреннән, 2017 ел белән чагыштырганда, 138 кешегә азрак үлгән (Спас районында 3 кешегә кимрәк).

Миокард инфарктыннан үлүчеләр саны күрсәткече 4,8%ка арткан, ул 100 мең кешегә 47,9 тәшкил иткән.

Спас муниципаль районында кан әйләнеше системасы авыруларыннан 170 кеше үлгән. Үлемнәр структурасында кан әйләнеше системасы авыруларына барлык үлем сәбәпләренең 50% туры килә, бу ТРның барлык районнары арасында иң югары күрсәткечләрнең берсе (867,9). Шул ук вакытта соңгы 5 елда хезмәткә яраклы яшьтәге кешеләрнең йөрәк-кан тамыры авыруларыннан үлүе кимүдә уңай динамика күзәтелә.

Хәзерге вакытта районда артериаль гипертониядән җәва чигүче 963 кеше теркәлгән. Әмма бу тулы исемлек түгел, чөнки мондый авыруларны диспансер исәбенә кую тулысынча үткәрелмәгән. Бүген халыкка өстәмә профилактик тикшерү уздыруга кискен ихтыяҗ бар. Мондый авыруларны ачыклауда ФАПларга һәм гомуми практика табибларына зур роль бирелә.

### 1.5.2. Яман шешләрдән үлү проблемасына сыйфатлама

Татарстан Республикасы буенча яман шешләрдән үлү күрсәткече 2018 елда 7,9%ка арткан һәм 100 мең кешегә 193,3 очрак тәшкил иткән (2017 елда – 179,2). Үлемнең гомуми структурасында яман шешләрдән үлү 16,2% тәшкил итә.

2018 елда үлгән авыруларның абсолют саны 7463 кеше тәшкил итә һәм 2017 ел күрсәткеченнән (6877) 576 кешегә арта. Үлем очраклары санының төп үсеше ирләрнең җенес органнарындагы яман шеш (27,6%ка), сулыш органнары (9,9%ка), ашкайнату органнары (8,7%ка) яман шеше хисабына булган.

Яшь категорияләре чагыштырмасында төп үсеш пенсия яшендәге кешеләр арасында – 656 кеше, яки 12,3%.

Хезмәткә яраклы халык арасында үлем структурасында яман шеш авырулары өченче урынны алып тора (15,3%) – тиешле яшьтәге 100 мең кешегә 74,1 очрак. Халыкның яман шешләрдән үлүенең иң югары күрсәткечләре Спас муниципаль районында билгеләнгән (265,5).

Авырулар структурасында яман шешләрнең түбәндәгечә локальләшүе өстенлек итә: сөт бизләре (12,7%); меланомалы тән тиресе (12,4%); юан эчәк (11,1%); үпкәләр (9,9%), мәни бизе (9,3%); ашказаны (7,1%). Мондый локальләшүләр халыкның онкология авырулары структурасында 62,5% тәшкил итә. 2017 ел белән чагыштырганда, сөт бизләрендәге яман шеш, меланомалы тире яман шешен уздырып, 2 нче урыннан 1 нчегә күчкән. 2017 елда ирләрдә мәни бизе яман шешнең иң күп локальләшкән урыны булып тора – 18,8%. Хатын-кызлар арасында рак сөт бизләрендә аеруча еш ачыклана (22,4%).

ТРда һәр 43 нче кеше яман шеш диагнозы белән исәптә тора. 5 һәм аннан артыграк ел исәптә торучылар 2018 елда 55,3% тәшкил иткән (2017 ел – 54,8%, РФдә – 52,4%).

Бер ел эчендә үлүчеләр саны 0,6%ка кимеп, 26,5% тәшкил иткән. Әмма Спас районында бер елда үлү очраклары (32,4%) республика дәрәҗәсеннән артып китә.

Яман шешләрнең азуында югары күрсәткечләр аеруча сөт һәм мәни бизләре, аналык муентыгы рагының визуаль төрләренә карата иртә диагностикага һәм профилактикага юнәлтелгән чараларны активлаштыру зарурлыгы турында сөйли.

Хатын-кызларның яман шештән үлеме структурасында сөт бизләре рагы беренче урында тора. Шуңа бәйле рәвештә чирне иртә стадияләрдә дөрес ачыкларга мөмкинлек бирүче маммография скринингы аеруча зур әһәмияткә ия. Скрининг уңышын тәэмин итүнең мәҗбүри шарты – тикшерелргә тиешле хатын-кызларны колачлау 70%тан ким булмаска тиеш.

Онкология авырулары очракларының 1/3 аналык муентыгы рагына туры килә. Бу уңайдан фонлы авыруларны, рак алды торышын һәм яман шешне клиникага чаклы стадиядә ачыкларга мөмкинлек бирүче скринингка һәм аларны вакытында дәвалау хисабына рак барлыкка килүне кисәтүгә мөһим роль бирелә. Аналык муентыгы яман шеше скринингын 18 яшьтән башлап хатын-кызлар өч елга бер тапкыр узарга тиеш, шул ук вакытта процедураның 80% хатын-кызларны колачлавы зарур.

Районда мәни бизе рагы ирләрдә онкология авырулары структурасында икенче урынны били. Бүген мәни бизе рагын иртә диагностикалауга юнәлтелгән скрининг тикшерүләрен даими үткәргән очракта, иртә стадияләрне ачыклау саны арта, ракның метастатик төрләре ачыкланмый диярлек. Даими тикшерү узган ирләрдә простата рагыннан үлү ихтималы 3 тапкыр кими.

Районда үлем структурасында яман шешләр өлешенә 9,5-14,9 процент туры килә.

### 1.5.3. <u>Тышкы сәбәпләрдән һәм җәрәхәтләрдән үлү проблемасына сыйфатлама</u>

Травматизм һәм аннан соңгы нәтиҗәләр иң мөһим медик-социаль проблемаларның берсе булып тора.

Татарстан Республикасы буенча үлем структурасында тышкы сәбәпләрдән үлү өченче урында (бер өлеше – 8,1%), 2018 елда күрсәткеч, 2017 ел белән чагыштырганда, 13,7%ка кимегән; күрсәткеч 100 мең кешегә 82,9 очрак тәшкил иткән. Спас муниципаль районында тышкы сәбәпләрдән үлү күрсәткече 53%ка яки 2017 ел белән чагыштырганда 1,8 мәртәбә арткан (2017 елда 24 кеше үлгән, 2018 елда – 43 кеше).

Спас районында җәрәхәтләнүләр, агуланулар һәм кайбер тышкы йогынтылар үлемнәр структурасында 3 урында һәм ТРның барлык районнары арасында иң югары күрсәткечләрнең берсе (219,5) булып тора. Хезмәткә яраклы яшьтәге затларның инвалидлыкка беренчел чыгу сәбәпләре структурасында алар 3 нче позицияне били.

2018 елда ТРда үз-үзенә кул салудан үлүчеләр саны, 2017 ел белән чагыштырганда, 18,7%ка кимегән һәм 100 мең кешегә 14,3% очрак тәшкил иткән. Безнең кечкенә авыл районында соңгы елларда суицид сәбәпле якты дөньядан китүчеләр саны тотрыклы саклана, 2018 елда 1 балигъ булмаган бала үз-үзенә кул салган.

**13 нче таблица**

| **Еллар** | **Суицидлар саны** |
|---|---|
| 2014 | 9 |
| 2015 | 8 |
| 2016 | 8 |
| 2017 | 7 |
| 2018 | 7 |

### 1.5.4. Туберкулез белән авыру

**14 нче таблица**

| Еллар | Абсолют саннар | 100000 кешегә |
|---|---|---|
| 2015 | 17 | 82,7 |
| 2016 | 23 | 113,4 |
| 2017 | 17 | 85,6 |
| 2018 | 12 | 61,0 |

2018 елның 1 гыйнварына туберкулезга каршы кабинетта актив туберкулез белән 36 авыру, шул исәптән 19 кеше бацилла бүленеп чыгу, 36 кеше сулыш органнары туберкулезы белән исәптә торган. 2018 елда 11 кеше сулыш органы

туберкулезы, 1 кеше үпкәдән тыш туберкулез белән исәпкә алынган. 9 авыру флюорография ярдәмендә ачыкланган. Яңа ачыкланган авыруларны госпитальләштерү 75% тәшкил иткән.

Өченче исәп төркемендә 43 кеше тора, шул исәптән 41 кеше тикшерелеп дәваланган, бу 95,3 % тәшкил итә. Өченче төркемгә 13 кеше күчерелгән. Терелеп чыккан 24 кеше исәптән төшерелгән.

Күп еллар дәвамында туберкулезга бәйле хәл хәвефле кала бирә, әлеге чирдән үлүчеләр саны югары. Әмма туберкулездан үлүчеләр санын киметүдә уңай тенденция күзәтелә.

**15 нче таблица**

**Туберкулездан үлүчеләр**

| Еллар | Абсолют саннар | 100000 кешегә |
|---|---|---|
| 2015 | 5 | 24,3 |
| 2016 | 5 | 24,6 |
| 2017 | 3 | 24,6 |
| 2018 | 2 | 10,0 |

**16 нчы таблица**

**Гражданнарны флюорография тикшерүе белән колачлау**

| 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 |
|---|---|---|---|---|
| 99,8 | 98,9 | 99,8 | 99,6 | 99,1 |

Туберкулездан үлү очракларын җентекләп тикшергәндә шунысы ачыкланды: әлеге авыруларның бөтенесе – социаль имин булмаган затлар, күпләренең торыр урыны юк, бөтенесе дә исерткечләрне күп куллана һәм туберкулезга

каршы препаратлар белән стационарда да, амбулатор рәвештә дә дәваланырга теләми. Күчмә флюорографны җәлеп итүдә дә проблемалар чыга, районның ерактагы авыллары халкы аңа мохтаҗ.

### 1.5.5. Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме эшен, ФАПлар эшен оештыру

Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме хезмәте – сәламәтлек саклау системасында иң мөһим юнәлешләрнең берсе, аның социаль әһәмияте бәхетсезлек очраклары, кинәт чыккан авырулар һәм гадәттән тыш хәлләр аркасында ел саен арта бара.

2018 елда ашыгыч ярдәм барлыгы 6469 чакыруга барган, шул исәптән бәхетсезлек очраклары уңаеннан 739 тапкыр, кинәт авырып китү һәм хәл начараю аркасында – 5308. Районда ашыгыч медицина ярдәмен вакытында күрсәтү күрсәткече 82,3% (5321) тәшкил иткән.

Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәмен күрсәтү сыйфаты мәсьәләсе медицина кадрларын әзерләү дәрәҗәсе белән турыдан-туры бәйле. Ашыгыч ярдәмгә баруда урта звено белгечләре ярдәм күрсәтә.

Район халкының яртысыннан артыгы авыл җирлегендә яши, шуңа күрә медицина ярдәме күрсәтүдә фельдшер-акушер пунктларына зур роль бирелә. Соңгы 5 елда 6 модульле ФАП төзелеп, сафка бастырылды. Районның фельдшер-акушер пунктлары медицина персоналы белән тәэмин ителде, әмма күпләре медицина җиһазлары белән начар тәэмин ителгән. ФАП фельдшерлары беркетелгән торак пунктларда яшәүче халыкның сәламәтлеге өчен тулысынча җаваплылык тоймый. Аларның эшен тикшереп тотуны көчәйтү, ФАП фельдшерлары эшен бәяләү өчен индикатив күрсәткечләр кертү зарур.

### 1.5.6. Медицина кадрлары һәм җиһазлар белән тәэмин ителеш

Әлеге программа йөз тоткан киләсе эш – ул кадрлар. Дәвалау учреждениеләренең медицина кадрлары белән җитәрлек тәэмин ителмәве район халкына медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры чагыла, аны бүген тулы канлы, дип әйтеп булмый. Дәвалау-профилактика учреждениеләре тар белгечләргә (окулист, психиатр, нарколог, эндокринолог, невролог һ.б.лар), гомуми практика табибларына, терапевтларга кискен мохтаҗлык кичерә.

Районда барлыгы 28 яки 10 мең кешегә 14 табиб, 154 шәфкать туташы һәм 72 кече медицина персоналы эшли. Табибларның уртача яше 48 яшь. Яшь белгечләрне җәлеп итү зарур. 2018 ел дәвамында «Спас үзәк район хастаханәсе»

дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә 1 табиб килде. Кадрлар мәсьәләсен хәл итү максатында, Казан дәүләт медицина университетына безнең район мәктәпләренең 10 чыгарылыш укучысы максатчан юнәлеш буенча юлланды. Хәзер алар – КДМУ студентлары. Әмма максатчан юнәлеш буенча киткән студентларның, университетны тәмамлагач, Спас үзәк район хастаханәсенә кайтырга теләмәүләре белән бәйле җитди проблема килеп туды. Әйтик соңгы өч елда өч максатчан укыган студент эшкә урнашудан баш тартты.

Ничек кенә сәер булмасын, тик авыл районнарына эшкә килгәндә 50 яшькәчә яшь белгечнең бер миллион сум алуын күздә тоткан «Земский доктор» программасы районга кадрлар проблемасын хәл итәргә булышмый гына түгел, киресенчә, комачаулый да, чөнки Болгар – рәсми шәһәр санала һәм без бу программага эләкмибез. Эш урынын сайлаганда яшь табиблар, әлбәттә, башка дәвалау учреждениеләрен сайлый. Безгә альтернатив методлар эзләргә туры килә. Шул рәвешчә 2015 елда Спас үзәк район хастаханәсе территориясендә торак йортлар төзелеше проекты барлыкка килде. ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды җирне (85 сутый) тапшыруга үз ризалыгын бирде.

Хәзерге вакытта квалификацияле медицина ярдәме заманча җиһазлардан башка мөмкин түгел. Хәзер булган медицина техникасы әхлакый һәм физик яктан искергән. Район дәвалау-профилактика учреждениеләре медицина техникасын яңартуга кискен мохтаҗлык кичерә.

### 1.5.7. Халыкның репродуктив сәламәтлек торышы

Халыкның репродуктив сәламәтлегенә бәйле проблема турында сөйләгәндә, ел саен районда уртача 110 бала тууын әйтергә кирәк, шул исәптән йөклелек чоры әйбәт узган очраклар 30 проценттан артмый. Йөклелек патологиясе арасында төп проблема – анемия (барлык йөкле хатын-кызларның 38%ы). Моңа йөкле хатыннарның сәламәтлегенә булышлык итү өчен кирәкле тимер препаратлары, поливитаминнар һәм йодлы препаратлар җитмәү китерә. Өстәвенә, булачак аналарның сәламәт яшәү рәвеше алып бару дәрәҗәсенең түбән булуын, санитар-агарту эшенең җитәрлек оештырылмавын билгеләп үтәргә кирәк.

Йөкле хатыннарны хатын-кызлар консультациясенә вакытында исәпкә кую зур роль уйный. Йөкле хатын-кыз табибка никадәр иртәрәк күренә башласа, авыру бала табу куркынычы шулкадәр кимрәк була.

«Авыру ата-ананың сәламәт балалары булмый» дигән әйтем бар. Репродуктив сәламәтлекнең начараюы балалар сәламәтлегендә чагылмый калмый. 18 яшькәчә балаларның авыру дәрәҗәсе югары кала бирә.

